СОВЕТ ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

РЕШЕНИЕ | КАРАР

29.10.2020 | 2-16

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-

д. им. М. Вахитова

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020нче елның 6нчы августындагы 658нче номерлы карары, Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советының
2020нче елның 29нчы октябреннән
2-16нчы номерлы карарына
1нче кушымта

Җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең
вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет сәркатибе | 15292 |

1.1. Карарга 12нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге Советының
2020нче елның 29нчы октябреннән
2-16нчы номерлы карарына
12нче кушымта

Вахитов авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләк күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 15759 |

2. Әлеге карар 2020нче елның 1нче октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен Югары Ослан муниципаль районы Вахитов авыл җирлеге Советының законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге башлыгы Ф. Р. Кәримов